17. Khisamova, F. M. (2017). *Istoricheskaya grammatika tatarskogo yazyka. Fonetika. Morfologiya* [Historical Grammar of the Tatar Language. Phonetics. Morphology]. 182 p. Kazan', Tat. knizhn. izd. (In Russian)

18. Yusupov, F. Yu. (2023). *Dialekty Kazanskikh tatar* [Dialects of Kazan Tatars]. 993 p. Kazan', Tat. knizhn. izd. (In Russian)

19. Yusupova, A. Sh. (2008). *Dvuyazychnaya leksikografiya tatarskogo yazyka XIX veka* [Bilingual Lexicography of the Tatar Language of the 19th Century]. 410 p. Kazan', izd-vo Kazansk. gos. un-ta. (In Russian)

20. Nurieva, F. Sh. (2004). *Istoricheskie i lingvisticheskie usloviya formirovaniya tyurko-tatarskogo literaturnogo yazyka zolotoordynskogo perioda* [Historical and Linguistic Conditions for the Formation of the Turkic-Tatar Literary Language of the Golden Horde Period]. 376 p. Kazan', Kazan.gos.un-t. (In Russian)

21. Yusupov, A. F. (2022). *Yazykovaya sistema tatarskoi sufiiskoi poehzii XIX veka* [Linguistic System of Tatar Sufi Poetry of the 19th Century]. 448 p. Kazan', Ikhlas. (In Russian)

# КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНДА ТАТАР ТЕЛЕ ТАРИХЫ ФӘНЕН ӨЙРӘНҮ

**Халисә Хатыйп кызы Кузьмина,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
shirmanx@yandex.ru

**Фәнүзә Шәкүр кызы Нуриева,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
fanuzanurieva@yandex.ru

Татар әдәби теле – халкыбыз тарафыннан гасырлар дәвамында иҗат ителгән тиңдәшсез кыйммәтле хәзинәләребезнең берсе. Тел аралашу чарасы гына түгел, ул – халыкның рухи эшчәнлеген чагылдырган төп күрсәткеч. Шушы рухи байлык гасырлар дәвамында әдәби истәлекләрдә тупланып, һәр тарихи чорга хас традицияләрне, тел нормаларын, төрле иҗтимагый вакыйгаларны чагылдыра. Татар әдәби теленең язма ядкарьләре телен бөтен тулылыгы белән өйрәнү, үсеш закончалыкларын тикшерү Казан университеты татар теле кафедрасының фәнни юнәлешләре арасында чор таләп иткән актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. Бу – татар теле үсешен күз алдына китерү өчен генә түгел, ә телнең татар халкы этногенезында тоткан тарихи урынын билгеләү һәм хәзерге шартларда традицияләр җирлегендә татар телен дәүләт теле буларак яшәтү мәсьәләсен хәл итү белән дә бәйләнгән. Казан университетында татар теле тарихын төрле яктан җентекләп өйрәнүнең гасырдан артык вакытка сузылган тарихы бар. Әлеге мәкаләдә сүз татар теле тарихын өйрәнү юнәлешендә үзләренең җуелмас эзен калдырган күренекле галимнәр турында бара.

**Төп төшенчәләр:** татар әдәби теле тарихы фәне, татар галимнәре, татар теле кафедрасы, Казан университеты

## Кереш

Казан университеты бөтен дөньяга танылган күп кенә фәнни җәмгыятьләрнең үзәге булып тора. Ул Россиядә Мәскәү, Дерпт (Тарту), Вилен (Вильнюс) университетларыннан соң дүртенче университет булып ачыла һәм XIX гасырның 30-40 елларында ук көнчыгышны өйрәнү үзәкләренең берсенә әверелә. Бу вакытта фәлсәфә факультетында төрле кафедралардан җыелган Көнчыгыш

разряды барлыкка килә, соңыннан ул атказанган фәнни абруйлы ориенталистлары белән дан казана.

Казан элек-электән Көнчыгыш белән киң сәүдә элемтәләренә ия булган. Казан аша Иранга, Урта Азиягә һәм Ерак Көнчыгышка сәүдә юллары үткән, шуңа күрә Казанда көнчыгышны өйрәнү фәннәре университет ачылганчы ук үсеш ала башлый, бу исә Көнчыгыш разрядының барлыкка килүен һәм нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин иткән [1, б. 418]. XIX гасырның соңгы чирегендә исә университетта соңрак Казан лингвистика мәктәбе исеме белән аталган тел белеме мәктәбе булдырыла. И. А. Бодуэн де Куртенэ, Н. В. Крушевский, В. А. Богородицкий һәм башка галимнәр структур лингвистика, морфонология, лингвистик типология, психолингвистика юнәлешендә эзләнүләр алып бара.

1812 елда татар теле Казан университетының уку программасына кертелә. Соңрак, 1828 ел ахырында – 1829 ел башында университет ректоры Н.И. Лобачевский инициативасы белән Көнчыгыш разряды төзелә, аңа көнчыгыш телләре кафедрасы базасында формалаштырылган ике кафедра – төрек-татар һәм гарәп-фарсы телләре кафедрасы керә. Казан тюркология мәктәбенә нигез салучылар – И. С. Хәлфин, Х. Д. Френ, Ф. И. Эрдман, А.К. Казем-Бек, А. Троянский, И.Н. Березин, М. Мәхмүдов, А. Вагабов, М. Иванов, С. Кукляшев, К. Насыйри, Н. Ф. Катанов, В. В. Радлов һ.б. татар халкы тарихына һәм аның әдәби теле тарихына зур игътибар биргәннәр. Көнчыгыш разряд Санкт-Петербургка күчерелгәннән соң да татар телен укыту дәвам иткән.

Казан университетында татар теле тарихын өйрәнүне шартлы рәвештә өч чорга бүлеп карарга мөмкин. Беренче чор 1804–1917 елларны үз эченә ала, бу чор Көнчыгыш разряды яшәеше һәм аннан соңгы чорда татар телен өйрәнү белән бәйле. Икенче чорны совет чорында татар теле тарихын өйрәнү дип карарга мөмкин, ул 1917–1991 елларны үз эченә ала. Бу аралыкта 1944 елдан соңгы чор – татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылганнан соң дәвам иткән вакыт аеруча игътибарга лаек, чөнки бу вакытта тел тарихын өйрәнү аеруча җанланып китә. 2000 еллардан башлап бүгенге көнгә кадәр булган чорны XXI гасырда татар теле тарихын өйрәнү дип аталырга хаклы.

Һәр чорның үзенчәлекле үсеш этаплары булган, Казан университеты тюркологлары Россия күләмендә генә түгел, дөнья күләмендә дә танылуга ирешкәннәр.

**Тикшеренү материаллары һәм методлары**

Әлеге мәкаләдә Казан университетында татар теле һәм аның тарихын фәнни яссылыкта өйрәнүнең озак елларга сузылган тарихын тасвирлау, бу өлкәдә хезмәт куйган галимнәрне һәм аларның фәнни-педагогик мирасын барлау бурычы куела.

Тикшерүнең төп методлары буларак, биографик метод, тасвирлама, тарихи-чагыштырмалы һәм аксиологик методлар кулланылды. Биографик метод һәм тасвирлама методлар ярдәмендә татар теле тарихын өйрәнгән шәхесләр эшчәнлеген тикшерү эше башкарылды. Тарихи-чагыштырмалы һәм аксиологик методлар әлеге эшчәнлекне бүгенге көн һәм узган гасыр күзлегеннән бәяләргә ярдәм итте.

**Фикер алышу**

1804 елда Казан университеты үзенең беренче уку елын башлагач, аның штатында, уставка яраклы рәвештә, көнчыгыш телләре профессоры һәм татар теле лекторы булырга тиеш булган. Ул вакытта әле бернинди кафедралар турында сүз дә булмый. Укыту да программаларсыз һәм уку планнарыннан башка гына бара. Шулай ук факультетларга бүленешләр дә, белгечлекләр дә булмаган. Өч елдан соң гына, 1807 елда, көнчыгыш телләре кафедрасы эшли башлый, анда гарәп һәм фарсы телләре укытыла, аерым елларда яһүд һәм сүрия телләре өстәлә. Бу кафедраның җитәкчесе итеп, Германиянең Росток шәһәреннән килгән күренекле ориенталист һәм нумизмат Христиан Данилович Френ билгеләнә. Ул Казан университетында ун елга якын эшли. Бу вакыт эчендә Х. Д. Френ көнчыгыш фәннәрен укытуны киңәйтә, көнчыгышны һәрьяклап фәнни өйрәнүгә нигез сала. Ул нумизматика белән кызыксына башлый, Алтын Урда чорында басылган 400 дән артык тәңкә таба, алар буенча ханнарның исемнәрен торгызуга ирешә, Урда шәһәрләренең урнашуын һәм шул вакыттагы рус-татар мөнәсәбәтләрен һ.б. тикшерә. Френның укыту һәм фәнни эшчәнлегендә иң якын хезмәткәре Ибраһим Хәлфин була, ул 1811 елдан университетта татар теле лекторы, ә 1823 елдан Көнчыгыш сүз гыйлеме адъюнкты

булып эшли [1, б. 420]. Шуны да әйтергә кирәк: Казанда татар телен укытуда Хәлфиннәр династиясе 60 ел дәвамында эшчәнлек алып барган. Ибраһим Хәлфинның бабасы Сәгыйть Хәлфин Россиядә беренче рәсми көнчыгыш телләре укытучысы була. 1769 елда аңа Казан гимназиясендә татар телен укыту йөкләнә. 1785 елдан аның варисы булып улы Исхак (1785–1800) тора, Исхак үлеменнән соң татар телен укыту эшен Ибраһим Хәлфин (1800–1828) дәвам иткән.

Казан университетыннан Х. Д. Френ киткәннән соң, көнчыгыш телләрен һәм мәдәниятен өйрәнү көчсезләнә. Бары 1827 елда Н. И. Лобачевскийның университет җитәкчелегенә килүе генә «Көнчыгыш разряды» үсешенә уңай йогынты ясый. 1828 елда татар теле лектурасы төрек-татар теле кафедрасына үзгәртелә, беренче чорда аны Александр Касимович (Мирза) Казембек җитәкли. Университетта монгол, кытай, әрмән телләре дә укытыла башлый, тюркология үсеш ала. Лобачевский күп кенә Көнчыгыш телләрендә кульязмалар һәм иске китаплар фондын булдыруга нигез сала. Турыдан-туры Лобачевский ярдәмендә Көнчыгыш разряды көчләре белән китапханәдә бик сирәк очрый торган Көнчыгыш китаплары һәм кульязмалары җыелган, алар хәзерге вакытка кадәр гаять зур фәнни кыйммәткә ия. Күпсанлы татар кульязмалары арасында 1775 елда беренче Казан гимназиясенең татар теле укытучысы Сәгыйт Хәлфин тарафыннан төзелгән татар әлифбасы һәм грамматикасының чын нөсхәсе һәм рус-татар сүзлеге (ике томда) табылган. 1778 елда бу китап Петербургта басыла. Шулай ук татар теле курсы буенча 1824–1826 елларда Ибраһим Хәлфин тарафыннан укылган лекцияләрнең кульязмалары табылган. Галим төрки-татар тарихи чыганакларны бастыру эшен башлап җибәрүчеләрнең берсе булып тора. Ибраһим Хәлфин үзе тапкан һәм нәшриятка әзерләгән «Дастане Чыңгыз вә Аксак Тимер» (1819), «Шәҗәрәи әт-түрк» (1820), Х. М. Френ белән берлектә нәшер ителгән «Тимер Котлыг тархан ярлыгы» хезмәтләре төрле ил галимнәренең игътибарын җәлеп иткән.

Көнчыгыш белгечләре А. К. Казембек һәм И. Н. Березин төрки телләрне өйрәнүнең фәнни үсеше өчен күп эшләр башкарганнар. Мәсәлән, Казем-Бекның нәтиҗәле фәнни эшчәнлеге төрки халыкларның тарихын, әдәбиятын, дини карашларын һәм законнарын өйрәнүгә юнәлдерелсә, И.Н. Березин Көнчыгыш тарихи кульязмаларын җыюга һәм бастырып чыгаруга зур игътибар биргән, шуның нәтиҗәсендә ул бөтен дөньяга танылa. Үзе төзегән өч томлык «Көнчыгыш тарихчылары китапханәсе»ндә (1850–1851) И. Н. Березин татар тарихына караган «Шәйбани-намә» һәм «Җәмигъ-эт-тәварих», Әбелгазый ханга мөнәсәбәтле хезмәтләр бастыра. Ул Казан университетында 10 елдан артык төрек-татар теле кафедрасын җитәкли, төрек телен укыта, төрки халыклар тарихы һәм төрек әдәбияты буенча лекцияләр укый.

Казан татарларының көнкүрешен беренче тикшерүче, танылган натуралист һәм этнограф К. Ф. Фуксның нумизматик һәм этнографик хезмәтләрен дә искә алу мөһим. Белгечлеге буенча табиб Фукс күп вакытын җирле халыкларны, күбесенчә татарларны тикшерүгә юнәлтә. Ул татарлар белән якыннан аралаша, аларның телен өйрәнә, Казан шәһәренең татар бистәсендә татарлар арасында яши һәм үзенең күпьеллык күзәтүләрен соңрак этнография буенча язылган «Статистик һәм этнографик яссылыкта Казан татарлары» хезмәтендә бәян итә һәм гомумиләштерә. Бу эштә ул татарларның физик типажына, аларның икътисадына, тышкы көнкүрешенә, хатын-кызлар мәсьәләсенә, шигърияткә, мәдәнияткә һәм бәйрәмнәргә, мәктәпкә һәм мәгърифәткә, руслар белән татарлар арасындагы үзара мөнәсәбәтләргә зур игътибар бирә.

XIX гасырның беренче яртысында Казан университеты Көнчыгышны өйрәнү һәм Россиядә көнчыгыш телләрен укыту үзәге булып тора. Көнчыгыш разряд 1854 елга кадәр яши. Бу елның 22 октябрендә Сенат Указы нигезендә Казан университетында һәм I Казан гимназиясендә көнчыгыш телләрен укыту туктатыла. Соңгысында татар телен укыту калдырылган.

Указда разрядны ябу көнчыгыш телләрен уңышлы өйрәнү өчен аларны бер урында укытуны туплау кирәклеге белән аңлатыла. Бу урын Санкт-Петербург университеты булган, анда «бу киң белем тармагын үстерү өчен күбрәк акча һәм империянең башка урыннарына караганда күбрәк уку әсбаплары берләштерелгән». Шуңа бәйле рәвештә Санкт-Петербург университеты каршындагы көнчыгыш телләре бүлеге Көнчыгыш факультетына үзгәртелә, анда Казанның күп кенә көнчыгышны өйрәнүчеләре үз эшчәнлекләрен дәвам итә [2, б. 212].

XIX гасырның икенче яртысында татар теленең үсешенә караган төп мәсьәләләр татар телендә басма матбугат чарасы чыгаруга юнәлтелә. Казан университетының математика һәм тәҗрибә физикасы адъюнкты Иван Ипатович Запольский 1808 елда рус һәм татар телләрендә «Казанские известия» газетасын чыгару проекты белән чыгыш ясый, әмма татар телендә газета чыгаруга рөхсәт ала алмый. 1833 елдан Казан университеты вәкилләре яңадан татар телендә газета булдырырга тырышалар. Көнчыгыш разряды тәрбияләнүчесе Маркел Григорьевич Никольский «Бәхрел әхбар» («Хәбәрләр диңгезе») дип аталган газета чыгару өчен берничә тапкыр омтылыш ясый. 1864 елда татар телендә «Файда» журналын чыгару буенча танылган ориенталист Петр Иванович Пашино инициативасы да уңышсыз була. Бер елдан соң шул ук исемдәге газетаны Василий Степанович Курочкин чыгарырга тели, ләкин ул да бюрократик киртәләргә юлыга.

1863 елда күренекле татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри (1825–1902) Казан хәрби губернаторы исеменә татар телендә басма орган чыгарырга рөхсәт сорап гариза яза. Санкт-Петербург университетының төрки телләр укытучысы Хөсәен Фәйзханов (1823–1866) шундый ук омтылыш ясый.

XIX гасырның икенче яртысында гына да төрле инстанцияләргә татарлар өчен вакытлы басмалар оештырырга рөхсәт сорап, егермедән артык үтенеч килгән. Әмма бу омтылышлар төрле сәбәпләр белән кире кагылган.

Бары тик XX гасыр башындагы революцион вакыйгалар гына патша хакимиятен татар милли матбугатын чыгару мәсьәләсенә мөнәсәбәтен үзгәртергә мәҗбүр итә. Нәтиҗәдә, 1905 елның 2 сентябрендә Санкт-Петербургта татар телендә беренче газета – «Нур» газетасының беренче саны дөнья күрә. 1905 елдан 1917 елга кадәр Россия империясенең 17 шәһәрендә татар телендә 120дән артык газета һәм журнал чыга, әмма алар барысы да революцион вакыйгалардан соң үз эшчәнлеген туктата [3].

1917 елга кадәр Казан губернасында татар теле укытыла торган бердәнбер дөньяви югары уку йорты Казан университеты була. Бу уку йортының уку программалары төрки-татар сөйләмнәре курсын күздә тота, ул тарих-филология факультетының классик бүлегендә укыла. 1917 елгы революцияләр алдыннан бу курсны Көнчыгышны өйрәнүче танылган галим Н. Ф. Катанов укыта, ул монда экстраординар профессор вазифасын башкаручы булып хезмәт итә. 1910 елларда, Казан университетында Петербург университетының Көнчыгыш факультетын тәмамлаган Сергей Ефимович Малов эшли башлагач, «Төрек-татар сөйләмнәре» курсы шактый киңәя. Галим тел тарихына зур игътибар биргән, аның шул елларда ук төрки рун язмалары теле белән кызыксына башлавы билгеле [4, б. 109].

Совет властеның беренче елларында ук татар теле уку предметы буларак югары мәктәпкә актив кертелә башлый, бу татар тел белеме буенча фәнни һәм педагогик кадрлар әзерли торган берничә зур белем бирү институтын булдыруга китерә.

Татар теле һәм әдәбияты бүлеге Казан университетының тарих-филология факультетында 1944 елның көзендә ачыла. Тарих-филология факультетының Гыйльми советында фикер алышудан соң, 1945 елның 13 апрелендә татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире һәм доцент вазифасына танылган Россия һәм совет галиме Көнчыгышны өйрәнүче Марр Николай Яковлевичның укучысы Рабига Афзаловна Хәкимова сайлана [5, б. 104].

Р. А. Хәкимова бик яхшы оештыручы буларак танылa. Ул татар теле һәм әдәбияты кафедрасының 1945–1946 уку елына фәнни-тикшеренү эшенең юнәлешендә Шиһабетдин Мәрҗани һәм Муса Акъегетзадә әсәрләренең телен, Габдулла Тукайның тормыш эшчәнлеген өйрәнүне дәвам итәргә ниятли. Өлкән укытучы Сөнгатулла Нигъмәтулла улы Бикбулатов Мәхмүд Кашгарыйның «Дивану лөгат әт-төрк» сүзлеген анализлау белән шөгыльләнә. Доцентлар Шиһап Галим улы Рамазанов һәм Латыйф Җәләй улы Җәләлетдинов, өлкән укытучы Бәкер Гарифулла улы Яфаровлар татар теленә һәм аның тарихына караган лекцияләр укыйлар.

Н. Маррның тел теориясе кире кагылганнан соң, татар теле һәм әдәбияты кафедрасының да эш юнәлеше үзгәрә. Язма истәлекләрнең телен Иосиф Сталин тәгълиматларына яраклаштырып өйрәнү башлана. Мәсәлән, кафедра ассистенты Гаяз Мәһди улы Ишмөхәммәтовның темасы «XIV гасыр Болгар чоры истәлеге «Нәһҗ әл-фарадис» әсәренең теле иптәш Сталинның тел белеме мәсьәләләре буенча хезмәтләре яктысында» дип аталган. Кафедра әгъзалары совет чорына кадәрге һәм совет чоры татар әдәбияты вәкилләренең иҗатын өйрәнүгә

игътибарны юнәлтәләр, татар теленең тарихи морфологиясе (Латыйф Җәләй улы Җәләлетдинов), тел турында Сталин тәгълиматы яктылыгында татар теленең эчке үсеше законнары мәсьәләләре (Лотфи Исмәгыйль улы Яфаров) белән шөгыльләнәләр [6, б. 235].

Татар теле һәм әдәбияты кафедрасында даими рәвештә фәнни потенциалны арттыру буенча эш алып барыла. Мәсәлән, 1958 елның 31 декабрендә кафедрада Җәвад Диндар улы Алмазовның «XIII гасыр поэмасы Кыйса-и Йосыф – болгар-татар истәлеге» дип аталган диссертациясе уңышлы фикер алышу узганнан соң, ректорат алдында авторны 1959 елның 1 гыйнварыннан тулы штат берәмлегенә кертү турында үтенеч белән мөрәҗәгать итәргә карар кабул ителә. Аспирантураны уңышлы тәмамлаган, гарәп, фарсы һәм берничә төрки телне белгән Җәвад Алмазның югары уку йортында эшләү тәҗрибәсе дә була. Ул вакытта кафедра составына Хатыйп Госман, профессор Латыйф Җәләй, доцентлар Якуб Агишев, Мирфатыйх Зәкиев, Ибраһим Нуруллин, Зәет Мәҗитов, Үзбәк Байчура, укытучылар Мәхмүт Хәсәнов, Әнвәр Әфләтунов, Фуат Ганиев, Вахит Хаков, Гомәр Саттаров, Альберт Яхин һ.б. укытучылар керә. Киләчәктә бу исемнәр татар теле һәм әдәбияты белеме сәхифәләрендә татар халкының олы галимнәре буларак язылачак, 1950–60 нчы елларда исә алар әле үзләренең фәнни юлы башында гына торалар.

Татар теле кафедрасының күп кенә укытучылары XX гасыр дәвамында тел тарихы юнәлешендә аерым эзләнүләр алып барсалар да, татар теле тарихын фәнни юнәлештә өйрәнүгә нигез салган һәм университетта үзенең фәнни мәктәбен булдырган берничә галимне аерып күрсәтергә мөмкин. Болар – Латыйф Җәләй, Вахит Хаков, Алмазия Нуриева, Фәһимә Хисамова, Фәнүзә Нуриева. Татар теле ономастик системасын Гомәр Фәез улы Саттаров тарихи планда өйрәнүгә нигез сала һәм шулай ук Казан ономастика мәктәбен булдыра. Бүгенге көндә аның юлын шәкертләре – филология фәннәре докторы, профессор, татар теле белеме кафедрасы мөдире Гөлшат Рәис кызы Галиуллина һәм филология фәннәре кандидаты, доцент Һадиева Гөлфия Камил кызы дәвам итәләр [7, б. 418].

Татар теле буенча беренче филология фәннәре докторы Латыйф ага Җәләйнең (1929–1966) тормыш юлы искиткеч бай һәм катлаулы. Латыйф Җәләйнең фәнни эшчәнлеге 1929 елда башлана, шул ук елда аның балаларны тәрбияләү методикасы буенча беренче эше басылып чыга, шуннан соң ул татар телен укыту методикасы буенча берничә китап бастыра, татар әдәбияты буенча дәреслек-хрестоматия төзүдә дә катнаша. 1932 елда Латыйф Самара авыл хуҗалыгы техникумының аспирантурасына укырга керә, анда аспирантура ябылганнан соң, 1933 елда Казан педагогия институтының аспирантурасында укуын дәвам итә. 1935 елдан ул шунда ук татар диалектологиясе һәм тел тарихы буенча укыту эшен башлый. 1939 елдан 1962 елга кадәр Латыйф Җәләй Тел, әдәбият һәм тарих институтында татар теле секторын җитәкли. Бер үк вакытта югары уку йортларында – Казан педагогия институтында һәм Казан университетында татар диалектологиясе һәм татар теле тарихы фәннәрен укыта.

Халык сөйләмнәрен өйрәнгәндә, Л. Җәләй, беренче чиратта, әдәби тел тарихын һәм тарихи грамматиканы кирәкле тел материалы белән тәэмин итә, шуңа күрә ул татар әдәби теле тарихын һәм тарихи грамматиканы өйрәнү белән шөгыльләнә. 1938 елда галим «Татар теле тарихына караган кайбер материаллар» китабын бастыра һәм шул ук темага кандидатлык диссертациясе яклый. 1940–60 елларда ул татар теленең диалектологиясе, теле тарихы һәм тарихи грамматикасы буенча бердәнбер белгеч була. 1954 елда Л. Җәләй «Татар теленең тарихи буенча фонетикасы буенча материаллар» китабын бастыра [8]. Әлеге китап бүгенге көнгә кадәр үзенең актуальлеген югалтмаган. 1960 елда Л. Җәләй Казан университеты нәшриятына «Татар теленең тарихи морфологиясе буенча очерклар» китабының кульъязмасын тапшыра, тик бу китап ул вакытта басылып чыкмаган, аны Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты 2000 елда бастыра [9]. Казан университетында әлеге хезмәт студентларга бүгенге көндә дә татар теленең тарихи грамматикасы юнәлешендә татар телендә язылган беренче зур монографик хезмәт буларак тәкъдим ителә.

Латыйф ага Җәләйнең төп фәнни фикерләре татар халкының килеп чыгышын тел материалы нигезендә аңлатуга барып тоташа. Тел материалын этногенез күзлегеннән анализлаганда, Л. Җәләй кайбер галимнәрнең татарлар һәм аларның теле Алтай һәм Монголиядән килгән дигән нәтиҗәләре белән

килешми. Аның фикеренчә, татар теле төрле җирле төрки кабиләләргә караган җирле төрки сөйләшләрнең берләшүе нәтиҗәсендә формалаша. Ул татар теленең өч зур диалектын – Урта, Көнчыгыш һәм Көнбатыш диалектларын җентекләп өйрәнүгә аерым игътибар бирә, шулар нигезендә татар теленең җирле төрки сөйләшләр нигезендә формалашканын раслый.

Латыйф ага Җәләй татар теле тарихын өйрәнүнең фәнни нигезләрен булдырган һәм бу юнәлештә үзенең шәкертләрен тәрбияләгән олы галим. Аның шәкертләренең берсе – Казан университеты профессоры, филология фәннәре докторы Вахит Хаков (1926–2008) озак еллар дәвамында әдәби тел тарихын өйрәнеп, шулай ук тел тарихын социолингвистик юнәлештә өйрәнүгә нигез салган олпат галим.

Вахит Хөҗҗәт улы Хаков 1926 елның 16 августында Татарстан Республикасы Буа районының Урта Лаще (Күзби) авылында укытучы гаиләсендә туа. Унҗиде яшьлек егет Бөек Ватан сугышы елларында фронтка чакырыла, Монголиядә, Кытайда сугыша, анда беренче тапкыр руник язулар текстларын күрә. Демобилизациядән соң Буа районы авыл мәктәбендә укытучы булып эшли, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә, 1960 нчы елда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы аспирантураны тәмамлый. 1961 елда XX гасыр башы татар әдәби теле тарихы буенча кандидатлык, ә 1971 елда «Татар әдәби теле һәм аның стильләренең барлыкка килүе һәм үсеше» темасына докторлык диссертациясен диссертациясен яклый. 1965 елда аңа доцент, ә 1974 елда профессор исеме бирелә. 2008 нче елга кадәр Казан университетында татар теле кафедрасы профессоры, ә 1989–1994 нче елларда татар теле кафедрасы мөдире булып тора.

Вахит Хаковның төп фәнни кызыксынулары төрки (башлыча татар) әдәби телләр тарихы, аларның стилистик категорияләре үсеше, борынгы төрки һәм татар язма истәлекләре телен тикшерү өлкәсенә карый. Төрле елларда тел белеменең гомуми мәсьәләләре, лексикология, терминология, фразеология, орфографиия, этимология мәсьәләләрен тикшерә; уку-укыту методикасы, югары уку йортында һәм мәктәптә әдәби әсәрләрнең телен өйрәнү проблемалары белән шөгыльләнә [10], [11], [12].

Вахит Хөҗҗәт улы Хаков – татар теле кафедрасында студентларга озак еллар дәвамында татар әдәби теле тарихы буенча лекцияләр укыган һәм шушы юнәлештә үзенең фәнни мәктәбен булдырган, күпсанлы шәкертләр тәрбияләгән галим. Аның җитәкчелегендә 20гә якын кандидатлык диссертациясе якланган, 3 докторлык диссертациясенең фәнни консультанты булган. Озак еллар галим кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен яклау буенча Гыйльми совет составында эшли, «Тел белеме» бүлеге буенча «Татар энциклопедиясе»н төзүдә катнаша. 30 елдан артык республика радиотапшырулары буенча аның җитәкчелегендә һәм турыдан-туры үзенең катнашында татар теле һәм сөйләм культурасы буенча «Тел күрке − сүз» фәнни-популяр тапшыруы алып барыла, аның кулъязма материаллары ун томнан артык тәшкил итә. Профессор фәнни-педагогик һәм иҗтимагый эшчәнлеге өчен унсигез орден һәм медаль, күп кенә Мактау грамоталары һәм Рәхмәт хатлары белән бүләкләнгән [13, б. 5].

Татар теленең тарихи грамматикасы юнәлешендә эшчәнлек алып барган галимә – Алмазия Хаҗи кызы Нуриева. Ул унҗиде ел дәвамында – 1967–1984 елларда Казан университетының татар теле кафедрасында доцент булып эшли, мәктәп укучылары өчен күпсанлы дәреслекләр яза, озак еллар гамәлдә булган, кабат-кабат басылган татар орфографик сүзлеген төзи, 1975 нче елда галимәнең татар теленең тарихи грамматикасына караган «Татар теле тарихыннан материаллар. Лексикология, морфология. Студентлар өчен кулланма» әсбабы дөнья күрә [14]. Әлеге кулланма татар теленең моңа кадәр эшләнмәгән тарихи лексикологиясенә караган материалларның да бирелүе белән аерылып тора. Галимә ел тарихын өйрәнүдә чагыштырма-тарихи методка нигезләнеп; гомумалтай, гомумтөрки катламнарны тикшерү критерийларын ачыклый.

Алмазия Хаҗиевна Нуриевадан соң тарихи грамматика юнәлешен татар теле кафедрасында Фәһимә Миргали кызы Хисамова дәвам итә.

Фәһимә Миргали кызы Хисамова (1936–2018) – танылган галим, тел белгече, татар теле фонетикасы һәм морфологиясе, тарихи граммтикасы өлкәсендә фәнни хезмәтләр, уку программалары, дәреслекләр, методик кулланмалар авторы, Татарстанның атказанган укытучысы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе. Ул 1936 елның 1

декабрендә Татарстан Республикасының Ютазы районы Кәрәкәшле авылында туа. 1955–1960 елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Университетны тәмамлаганнан соң, җиде ел дәвамында Чүпрәле һәм Азнакай районнары мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. 1967–1970 елларда Казан дәүләт университетының татар теле кафедрасы каршында Д.Г. Тумашева фәнни җитәкчелегендә аспирантура уза. 1971 елда «Хәзерге татар әдәби телендә сыйфат фигыль» темасына кандидатлык диссертациясе, 1995 елда «Иске татар рәсми язуының гамәлдә булуы һәм үсүе (XVI – XIX гг. башы)» темасына филология фәннәре докторлыгына диссертация яклый.

Утыз елдан артык татар теле кафедрасында укытучы булып эшләү дәверендә галимә татар теленең фонетикасы һәм морфологиясе, тарихи грамматикасы буенча лекцияләр уку өчен методик әсбаплар, программалар һ. б. төзегән. Ул хәзерге татар теле структурасының төрле аспектлары буенча фәнни мәкаләләрнең һәм югары уку йорты өчен язылган «Хәзерге татар әдәби теле. Морфология» (2006) хезмәтенең авторы. Төрле җыентыкларда һәм журналларда басылган күпчелек мәкаләләре татар әдәби теле тарихы һәм тарихи грамматика мәсьәләләренә багышланган [15], [16]. 2017 елда дөнья күргән «Татар теленең тарихи грамматикасы: Фонетика. Морфология» хезмәте бүгенге көндә татар теленең тарихи грамматикасы фәне буенча татар телендә язылган санаулы хезмәтләрнең берсе [17]. Әлеге хезмәттә галимә тарихи грамматика буенча төрки тел белемендә булган теория һәм фаразларны татар теле тарихы яссылыгына күчереп, һәр күренешкә аңлатма бирә; татар теленең грамматик үсеш үзенчәлекләрен билгели, диалекталь күренешләргә тукталa. Татар теленең төрле диалектлары һәм сөйләшләре арасында барлыкка килгән уртак күренешләр ачыклана. Кыпчак төркеменә кергән татар телендә угыз телләренең саклануы кабилә телләренең тарихи тыгыз бәйләнеше белән аңлатыла. Шулай ук галимә телнең үз эчендә чагылыш тапкан тарихи үзгәрешләрне ачыклауга зур игътибар юнәлтә. Бу хезмәттә Фәһимә Миргали кызы озак еллар дәвамында татар теле кафедрасында татар теленең тарихи грамматикасы буенча алып барган лекция материалларына, шәхси күзәтүләренә, шулай ук татар теле тарихы белгечләре фикерләренә таяна.

Лингвистик география һәм ареал лингвистика методларына нигезләнеп, татар теленең диалектларын өйрәнү өлкәсендә зур уңышларга ирешкән танылган тел белгече, галим-диалектолог, филология фәннәре докторы, профессор Фәрит Йосыф улы Юсупов – 1939 нчы елның 15 маенда Яшел Үзән районы Зур Карауҗа авылында дөньяга килә. 1956–1961 елларда Казан университетының тарих-филология факультетының татар бүлеген тәмамлагач, 1964 елдан татар халкы күпләп яши торган төрле өлкәләргә экспедицияләр оештырып, халыкның җирле сөйләшләрен өйрәнә башлый. Тупланган материалларны фәнни эшкәртү юнәлешендә эш алып барган Фәрит Йосыф улы һәр монографиясендә татар сөйләшләрен формалаштырган этник төркемнәр тарихына җитди игътибар бирә. Күпьеллык фәнни эшчәнлеге тупланган «Казан татарлары шивәсе» хезмәтендә галим Казан ханлыгы чоры, Казан ханлыгы җимерелгәннән соң татар әдәби теленең нигезен тәшкил иткән, бай сөйләшләр системасынан торган казан татарлары шивәсенең барлыкка килү тарихын, аның авазлар системасын һәм грамматик төзелешен өйрәнә [18]. Танылган галим Россиянең иксез-чиксез киңлекләренә таралган татар сөйләшләренең фонетика, морфология һәм лексика өлкәсендә үзара зур уртаклыклары булуын ачыклый, әдәби тел системасы һәм җирле сөйләшләрнең бер-берсен баету һәм камилләшү процессы кичерүен билгели.

Филология фәннәре докторы, профессор Әлфия Шәүкәт кызы XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрне тикшереп, татар лексикографиясендә басма сүзлекләр төзелүнең сәбәпләрен бөтен Россия масштабындагы социаль, сәяси шартларга бәйләп аңлата. Рус һәм татар халкы арасында үзара сәүдә-икътисади, иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни бәйләнешләрнең яшәп килүе һәр ике телгә ихтыяҗ тудыра, шул сәбәпле ике тел байлыгын туплаган сүзлекләр нәшер ителә башлый. Казан дәүләт универститеты, Татарстан Милли китапханәләрендә, Мәскәү, Берлинның үзәк китапханәләре фондларыннан сүзлекләрне барлап, аларга тарихи-лингвистик анализ бирә. Галимә сүзлекләрдә теркәлгән лексик байлыкны килеп чыгышы, кулланылышы ягыннан тикшереп, әлеге чорда татар әдәби телен халыкның җанлы сөйләм теленә якынайту процессы башлануын билгели [19].

Татар һәм төрки тел гыйлеменең күренекле вәкилләре Диләрә Гариф кызы Тумашева һәм Әдһәм Рәхим улы Тенишевларның шәкерте, филология фәннәре докторы, профессор Фәнүзә Шәкүр кызы Нуриева да татар теле тарихы юнәлешендә үзенчәлекле фәнни юнәлеш барлыкка китергән галимәләрнең берсе.

Фәнүзә Шәкүр кызы Нуриева 1956 елның 8 мартында Баулы районының Иске Чүте авылында туа. Мәктәпне тәмамлаганнан соң (1974) Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Уку дәверендә филология фәннәре докторы, профессор, факультет деканы Д. Г. Тумашеваның турыдан-туры җитәкчелегендә аның фәнни тикшеренүләре башлана. Шәхси уку планы буенча шөгыльләнә, көнчыгыш телләрен гарәп, төрек телләрен өйрәнә. Аннары Баулы районы Байрәки-Тамак авылы мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. 1983 елда Галимҗан Ибраһимов исемендәге ИЯЛИ КФАН каршындагы аспирантурага укырга керә. Россия Фәннәр Академиясенең (РФА) әгъза-корреспонденты, РФА Тел белеме институтының тюркология һәм монголистика лабораториясе мөдире Э. Р. Тенишев һәм филология фәннәре докторы Ф. С. Хәкимҗанов җитәкчелегендә XIV гасыр төрки-татар язма истәлеге Мәхмүт әл-Болгари әс-Сараиның «Нәһҗ әл-Фәрадис» әсәрен (1358) өйрәнә һәм кандидатлык диссертациясе яклый.

2004 елда Казан дәүләт университеты нәшриятында нәшер ителгән «Исторические и лингвистические условия формирования тюрко-татарского литературного языка золото-ордынского периода» китабы докторлык диссертациясенең нигезен тәшкил итә [20]. Әлеге хезмәттә Алтын Урданың ике йөз еллык әдәби-мәдәни мирасы, бер яктан, элекке әдәби традицияләрне иҗади куллану нәтиҗәсе буларак тикшерелә, икенче яктан, гомуми әдәби телләр үсеше өчен хас закончалык – төрки әдәби телнең үзгәреш факты билгеләнә. Җентекле тикшеренүләр Ф. Нуриевага күп кенә тел күренешләренә яңача якын килергә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, төрки тел белемендә кабул ителгән «катнаш тел» термины галимнәр тарафыннан төрлечә аңлатыла. Галимә аны «норма һәм вариантлык» итеп карау кирәклекне күтәрә. Бу чор өчен әдәби нормаларны билгеләү максатында, автор бик күп статистик күзәтүләр ясый, ягъни һәрберсе 200-300 биттән торган зур күләмле әдәби текстларны карый, алардагы норма һәм вариантлылыкны билгели. Тугыз истәлекне бердәм таләпләр нигезендә тикшереп, Ф. Нуриева караханид-уйгур традицияле төрки әдәби телгә кыпчак формалары үтеп кереп, Алтын Урда чорында яңа региональ әдәби тел, иске татар әдәби теленең бер варианты, Идел буе төрки әдәби тел барлыкка килүен нигезли. Аның бу өлкәдәге фәнни тикшеренүләре төрки тел белемендә зур бәя ала, гомумтөрки мәсьәләләргә багышланган мәкаләләре төрек, инглиз телләренә тәрҗемә ителеп, чит ил басмаларында урын ала, коллектив монографияләрдә күп кенә махсус хезмәтләре басыла.

Бүгенге көндә дә татар теле кафедрасында татар теле тарихын өйрәнү юнәлеше дәвам итә. Йосыпов Айрат Фаик улы 2003 елдан Казан федераль университетында «Татар телендә гарәп-фарсы традицияләре», «Ислам белеме», «Гарәп теле нигезләре», «Татар суфичылык поэзиясенең стилистик эволюциясе», «Суфи әдәбияты теле» һ.б. курслар алып бара, 2004 елда «XIX гасырның беренче яртысында суфи шагыйрь Шәмсетдин Зәки әсәрләренең морфологик үзенчәлекләре» дип аталган кандидатлык диссертациясе, 2022 елда «XIX гасыр татар суфи шигърияте телен атрибуцияләү» темасына докторлык диссертациясе яклый [21]. Бүгенге көндә Айрат Фаик улы – татар теле белеме кафедрасының әйдәп баручы укытучыларыннан берсе, филология фәннәре докторы.

Вахит Хаковның шәкерте Халисә Хатыйп кызы Кузьмина да татар теле тарихын, аның Болгар чоры язма истәлекләре телен өйрәнүче галимә. 1998 нче елда ул «Кол Галинең „Кыйссаи Йосыф“ әсәренең тел һәм стиль үзенчәлекләре (XIII г.)» дип аталган темага кандидатлык диссертациясе яклый һәм шул вакытлардан бирле татар әдәби теле тарихы, татар теленең тарихи грамматикасы буенча студентларга дәресләр алып бара, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре белән берлектә татар әдәби теленең тарихи үсеше турында монографияләр язуда катнаша.

Татар дөньясында әдәби тел тарихы буенча төрле тарихи чорларга караган язма истәлекләр телен тикшереп, күпсанлы диссертацияләр яклана, китап-монографияләр дөнья күрә. Тел тарихын өйрәнүдә Татарстан Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

хезмәткәрләренең дә өлеше бик зур. Әлеге юнәлештә хезмәт иткән олпат галимнәребездән Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев, Хәлиф Рәхим улы Курбатов, Илида Басыйр кызы Бәширова, Марсель Ибраһим улы Әхмәтҗанов, Рифкать Газизҗан улы Әхмәтьянов, Фәрит Сабирҗан улы Хәкимҗанов һ.б. атарга мөмкин. Аларның юлын бүгенге көндә филология фәннәре докторлары Бәхтияр Миңнуллин, Рифат Мирхаев, филология фәннәре кандидаты Миләүшә Вәлиева һ. б. дәвам итә.

Татар теле белеме кафедрасы бүгенге көндә дә тел тарихы белгечләре әзерләүгә күп көч куя. Бу юнәлештә Әлфия Исхакова, Гөлназ Гайнуллина, Гөлназ Закирова, Альбина Исламова, Энҗе Кадыйрова, Әлфия Маннапова, Рәзинә Мөхәммәтрәхимова, Фәнис Мөхәммәтшин, Салахова Ильвира һәм башка авторларның тел тарихы буенча якланган кандидатлык диссертацияләрен күрсәтергә мөмкин. Энҗе Хәнәфи кызы Кадыйрова һәм Гөлназ Фоат кызы Гайнуллина шактый озак вакыт татар теле белеме кафедрасында доцент булып эшлиләр; татар әдәби теле тарихы, аның Казан ханлыгы һәм Алтын Урда чоры тел үзенчәлекләрен күпсанлы мәкаләләрдә, программаларда һәм уку-укыту әсбапларында чагылдыралар.

## Төп нәтиҗәләр

2024 нче елда Казан университетының татар теле белеме кафедрасы үзенең 80 еллык юбилеен билгеләп үтә. Бу вакыт эчендә әлеге кафедрада озак еллар дәвамында хезмәт иткән галимнәр тарафыннан татар теле тарихын ике яссылыкта – татар әдәби теле тарихы һәм тарихи грамматика юнәлешләрендә өйрәнү башкарылган. Бу юнәлешләр студентларга белем бирү өчен монографияләр, уку-укыту әсбаплары һәм программалар белән ныгытылган, бүгенге көндә тотрыклы система буларак оешкан. Татар теле белеме кафедрасында татар теле тарихы буенча дистәләгән диссертацияләр тикшерү узган һәм диссертация яклау советларында якланган, фән кандидатлары һәм докторлары барлыкка килгән. Татар теле тарихын өйрәнүне системага салган галимнәрнең мирасына һәм якты истәлегенә багышланган фәнни конференцияләр, семинарлар, искә алу кичәләре үткәрелә, конференция материаллары җыентык булып басылып чыга.

Шул рәвешле, хәзерге вакытта татар теле тарихын өйрәнүчеләр тырышлыгы белән татар әдәби теленең формалашу һәм үсеш процессының шактый төзек системасы, шулай ук әдәби традицияләр барлыгы турындагы күзаллау булдырылган, татар теленең үсеш үзенчәлеге һәм аның төп характеристикалары ачыкланган.

**Әдәбият**


1. *Шофман А. С., Шамов Г. Ф.* Восточный разряд Казанского университета (красткий очерк) // Очерки по истории русского востоковедения. М., Изд-во АН, 1956. С. 417-448.
2. *Тумашева Д. Г.* Развитие татарского языкознания в Казанском университете (1944–1995) // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1996. №1/2. С. 212-216.
3. *Гарифуллин В. З. Сабирова Л. Р.* Татарская журналистика: исторический опыт и перспективы развития // Учен. зап. Казан. ун-та. Сер. Гуманит. науки. 2015. Том 157, кн.4. С. 54–61.
4. *Бушуева Л. А.* Преподавание татарского языка в вузах Казани в 1920-е гг.: от древнетюркской письменности к Дальтон-плану // Историческая этнология. 2021. Т. 6. № 2. С. 208–220.
5. *Замалетдинов Р. Р., Хабутдинова М. М.* История создания отделения татарского языка и литературы в Казанском государственном университете в воспоминаниях преподавателей и первых студентов // Tatarica. 2018. № 1 (10). С. 91–113.
6. *Ханипова И. И.* Создание кафедры татарского языка и литературы в Казанском государственном университете и ее деятельность с середины 1940-х – 1950-е гг. (по материалам Государственного архива Республики Татарстан) // Историческая этнология. 2021. Т. 6. № 2. С. 231–242.
7. *Галиуллина Г. Р., Кадирова Э. Х., Хадиева Г. К.* Современная татарская разговорная речь: идентификационные признаки и социальная дифференциация. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2020. 222 с.
8. *Җәләй Җ. З.* Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. Казан, 1954. 108 б.
9. *Җәләй Җ. З.* Татар теленең тарихи морфологиясе: очерклар. – Казан, 2000. 287 б.
10. *Хаков В. Х.* Татар әдәби теленең совет чорында үсеше. 20–30 нчы еллар (Развитие татарского литературного языка в советский период. 20–30-е годы). Казан: КДУ нәшр., 1985. 150 б.
11. *Хаков В. Х.* Татар әдәби теле тарихы (Әдәби телнең үсешен диахроник һәм синхроник аспектта тикшерү). Казан. 1993. 329 б.
12. *Хаков В. Х.* Тел – тарих көзгесе. Татар әдәби теленең борынгы чорлардан башлап үсеш тарихыннан. Казань: Тат. кит. нәшр., 2003. 296 б.
13. *Кузьмина Х. Х.* Вклад заслуженного профессора казанского университета В. Х. Хакова в

изучение развития татарского литературного языка // Хаковские чтения – 2023: материалы Международной научно-практической конференции молодых ученых, посвященной памяти заслуженного профессора Казанского университета Вахита Хозятовича Хакова (Казань, 26–27 октября 2023 г.) / под общ. ред. Г. Р. Галиуллиной. Электронные сетевые данные (1 файл: 515 Кб). Казань: Издательство Казанского университета, 2023. С. 3–5.

14. *Нуриева А. Х.* Татар теле тарихыннан материаллар. Лексикология, морфология. Студентлар өчен кулланма. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1975. 97 б.

15. *Хисамова Ф. М.* Функционирование и развитие старотатарской деловой письменности XVI – XVII вв. Казань: Изд-во КГУ, 1990. 152 с.

16. *Хисамова Ф. М.* Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI – начало XIX вв.). Казань: Мастер-Лайн, 1999. 407 с.

17. *Хисамова Ф. М.* Татар теленең тарихи грамматикасы. Фонетика. Морфология. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2017. 182 б.

18. *Юсупов Ф. Ю.* Казан татарлары шивәсе. Казан: татар кит.нәшр., 2023. 993 б.

19. *Юсупова А. Ш.* Двуязычная лексикография татарского языка XIX века. Казань: Изд-во Казанск. гос. ун-та, 2008. 410 с.

20. *Нуриева Ф. Ш.* Исторические и лингвистические условия формирования тюрко-татарского литературного языка золотоордынского периода. Казань: Казан.гос.ун-т. 2004. 376 с.

21. *Юсупов А. Ф.* Языковая система татарской суфийской поэзии XIX века. Казань: Ихлас, 2022. 448 с.

---

# ИЗУЧЕНИЕ ИСТОРИИ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА В КАЗАНСКОМ УНИВЕРСИТЕТЕ

**Халиса Хатиповна Кузьмина**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
shirmanx@yandex.ru.

**Фануза Шакуровна Нуриева**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
fanuzanurieva@yandex.ru.

Татарский литературный язык – одна из самых главных ценностей, созданных народом на протяжении веков. Язык является не только средством общения, но и основным показателем духовной деятельности народа. Духовное богатство веками накапливалось в литературных письменных памятниках, отражая традиции, языковые нормы, различные общественные события, присущие каждому историческому периоду. Изучение языка письменных памятников татарского литературного языка во всей его полноте, исследование закономерностей его развития является одним из актуальных научных направлений кафедры татарского языкознания Казанского университета. Оно связано не только с представлением развития татарского языка, но и с определением исторического места языка в этногенезе татарского народа и решением вопроса о существовании татарского языка как государственного на базе традиций в современных условиях. Ученые Казанского университета на протяжении более века занимаются всесторонним изучением истории татарского языка. В данной статье речь идет о наследии выдающихся ученых, оставивших свой неизгладимый след в изучении истории татарского языка.

**Ключевые слова:** история татарского литературного языка, татарские ученые, кафедра татарского языкознания, Казанский университет